| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**12.04.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 844** |

Җиңү көнен бәйрәм итүгә бәйле рәвештә Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә) бер тапкыр бирелә торган түләүләр оештыру турында

Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә) Бөек Җиңү көнен бәйрәм иту уңаеннан, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында ассигнованиеләре каралган, «2022 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» 2021 елның 17 декабрендәге 117 номерлы карарын үтәү йөзеннән, финанс ярдәме күрсәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә Зеленодольск муниципаль район Башкарма комитетына җирлекләр буенча теркәлгән Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарын (тол ирләрен), шулай ук, 2022 елның 1 гыйнварыннан алып, югарыда күрсәтелгән категориядәге вафат булган гражданнарның исемлекләрен 2022 елның 25 апреленә кадәр булган вакыт эчендә тапшырырга тәкъдим итәргә.
2. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ 2022 елга Зеленодольск муниципаль районының расланган бюджеты чикләрендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән түләүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә 2022 елның 9 маена кадәр бер кешегә түләү ведомостьлары нигезендә 2000,00 (ике мең) сум күләмендә түләүләр башкарырга.
4. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә) бер тапкыр бирелә торган түләүләрне тапшыруны оештыруда ЗМР Башкарма комитетына ярдәм итүне Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре Башлыкларына һәм ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы «Рәхәт» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге ДАУСО тәкъдим итәргә.
5. «Җиңү көнен бәйрәм итүгә бәйле рәвештә Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына

(тол ирләренә) бер тапкыр бирелә торган түләүләр оештыру турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге 801 номерлы карарын үз көчләрен югалткан дип танырга.

6. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/ ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев